| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ГЛАВА<br>Старосляковского сельского поселения<br>Агрызского муниципального района | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>Әгерже муниципаль районы<br>Иске Эсләк авыл җирлеге<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР** |

09.10.2020 Үтәгән № 2

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районынын Үтәгән авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының Иске Эсләк авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының Иске Эсләк авыл җирлеге башлыгы

к а р а р и т т е:

1. Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының «Иске Эсләк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Үтәгән торак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2020 елның 23 октябрендә 10 сәг 30 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорау итеп расларга: «2021 елда Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының «Иске Эсләк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Үтәгән торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

- Үтәгән авылында Үзәк урамы, Дуслык урамы буенча юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Үтәгән авылында урам яктырткычлары сатып алу, диодлы лампалар кую, килешү буенча эшләр өчен түләү;

- Үтәгән авылында халыкны су белән тәэмин итүне тоту (су җыю системасының өзеклеген бетерү, экскаваторны арендага алу шартнамәсе буенча түләү, тирәнлек насослар һәм материаллар сатып алу);

- Үтәгән авылындагы урамнарны кардан чистарту.

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Гражданнар җыенын Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Үтәгән авылы, Үзәк урамы адресы буенча - авыл клубы янындагы мәйданчыкта үткәрергә.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иске Эсләк авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

5. Әлеге карарны “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иске Эсләк авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы И.Н. ГАФАРОВ